ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕПОЛЯНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЗУР ПОЛЯНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с.Зур Полянка **КАРАР**

**09.11.2023** **№17**

**«Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2012 елның 29 июлендәге 2 номерлы Зур Полянка авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актларының һәм норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында, кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контроль буенча чаралар үткәргәндә үтәлә торган мәҗбүри таләпләр булган башкарма хакимиятнең федераль органнарының норматив хокукый актларын гамәлдән чыгару турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 11 июлендәге 1036 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты

карар бирә:

1.Зур Полянка авыл җирлеге Башкарма комитетының 2012 елның 29 июлендәге 2 номерлы «Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» карарына 1 нче кушымтаның 4 нче «Сатучыларга таләпләр» бүлегендә сүзләр:
«-19.01.1998 елгы 55 номерлы Аерым төр товарларны сату таләпләрен һәм кагыйдәләрен үтәргә,» төшереп калдырырга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.
3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Зур Полянка авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Н.И. Александрова**